| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** / **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 652-81/тэ-2023

Нурлат муниципаль районының «Нурлат җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2024 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 №58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районының «Нурлат җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Нурлат җылылык челтәрләре» АҖ) тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) әлеге карарның 1 кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 652-81/тэ-2023
карарына кушымта

«Нурлат җылылык челтәрләре» АҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2024 елга календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см$^2$ кадәр | югары 13,0 кг/см$^2$ | |
| | Нурлат муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Нурлат җылылык челтәрләре» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1 856,52 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2 075,59 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <*> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 2 227,82 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2 490,71 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге